ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2020 Казан ш. № 435-127/тп-2020

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек бирәмлегенә хисаплаганда «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2021 елга түләү билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау), җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтләрдән дискриминацион булмаган файдалану мөмкинлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек бирәмлегенә хисаплаганда «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2020 № 435-127/тп-2020
карарына 1 нче кушымта

## Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә хисаплаганда «Алабуга җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү

мең сум/Гкал/сәг (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча)

| Тәртип саны | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 6,499 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның (П2.1) объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) гайре), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өслегеннән) салу | |
| 2.1.1 | 250 мм кадәр | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | – |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал белән салу | |
| 2.2.1.1 | 250 мм кадәр | - |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 250 мм кадәр | 3 417,345 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзү (үзгәртеп кору) чыгымнары (П2.2) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге